| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**БОЕРЫК** **БОЕРЫК**

13.07.2017 Казан ш. № 168

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пункты нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелүнең кушымтада бирелгән тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 2017 елның
«13» июлендәге № 167 боерыгы
белән расланды

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү

ТӘРТИБЕ

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында (алга таба – Дәүләт комитеты) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп эшләнде.

Әлеге Тәртип эш бирүче тарафыннан Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәрләре) иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте (алга таба – коммерциячел булмаган оешма) белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү процедурасын регламентлый.

Әлеге тәртип Дәүләт комитетында аларны эшкә алучының вәкиле булып Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе (алга таба – Дәүләт комитеты рәисе) торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә кагыла.

2. Коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турында гариза (алга таба – Гариза) граждан хезмәткәре тарафыннан язмача рәвештә, шушы Тәртипкә 1 нче кушымтада бирелгән формада төзелә.

3. Граждан хезмәткәре Гаризаны коррупциячел һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны кергән көнендә шушы Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карау эшен гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны алдан карау барышында Җаваплы зат Гаризаны тапшырган граждан хезмәткәреннән коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуының планлаштырылган функцияләрен билгеләүче язмача аңлатмаларны һәм документларны сорарга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

6. Гариза теркәлгән көннән соңгы биш эш көненнән дә соңга калмыйча Җаваплы зат Гаризаны, Бәяләмәне һәм башка материалларны (булган очракта) теркәп, коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә (алга таба – Дәүләт комитеты рәисе) (рәисе урынбасарына) карау өчен тапшыра.

Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) Гаризаны алган көннән соңгы ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) карары кабул ителгән көннән соңгы ике эш көне дәвамында граждан хезмәткәренә Гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа имза куйдыртып, Дәүләт комитетының кадрлар бүлеге мөһере белән таныкланган Гаризаның күчермәсен Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) резолюциясе белән тапшыра. Гаризаның Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) резолюциясе куелган төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

___________________________

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә

1 нче кушымта

____________________________________

____________________________________

(Ф.И.А., били торган вазыйфа һәм структур

____________________________________

бүлекчә, яшәгән урын адресы

____________________________________

телефон номеры)

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турында

ГАРИЗА

Миңа (кирәклесенең астына сызарга)____________________________________________

(иҗтимагый оешманың, торак,

______________________________________________________________________________

торак-төзелеш, гараж кооперативының, яшелчәчелек, бакчачылык,

______________________________________________________________________________

дача кулланучылар кооперативының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең аталышы)

____________________________________________________сыйфатында түләүсез нигездә

______________________________________________________________________________

(бер кеше кулындагы башкарма органның яисә идарә коллегиаль органының аталышы)

______________________________________белән идарә итүдә катнашырга, идарә коллегиаль органы составына керергә рөхсәт бирүне сорыйм

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | __________________ | _________________________ |
| (дата) | (имза) | (фамилия, инициаллар) |

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә
2 нче кушымта

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт
граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә
бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга
яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт
бирелү турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Үтенеч язуын бирүченең Ф.И.А., вазыйфасы | Үтенеч язуын бирүченең имзасы | Теркәүченең Ф.И.А. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |